**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«18» апрель 2025 ел Яр Чаллы № 1269

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 апрелендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 1261 номерлы карары белән расланган административ комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Тукай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 23 апрелендәге 9/7 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 апрелендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 1261 номерлы карары белән расланган административ комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Тукай муниципаль районы административ комиссиясе составыннан чыгарырга:

Хәбибуллина Алинә Өхнәф кызын;

- Тукай муниципаль районы административ комиссиясе составына кертергә:

Рамазанова Гөлназ Фәнис кызын – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының баш белгече, административ комиссиянең җаваплы секретаре;

Солтанова Айгөл Җәүдәт кызын – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы.

2. Тукай муниципаль районының административ комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев